ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2026 с.Старое Дрожжаное № 414

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль берәмлекләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы номерлы карары, «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 елның 07 июнендәге 251 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль учреждениеләрнең авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче белгечләренә түбәндәге категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары билгеләргә:

- мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүчеләргә Татарстан Республикасы Законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормалары һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары кысаларында торак, җылылык, яктылык өчен түләү чыгымнарын - 100 проценты күләмендә билгеләргә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы авыл җирендә урнашкан мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән һәм шунда яшәгән, шулай ук Россия Федерациясе системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмаган хезмәткәрләрдә саклана.

2. Билгеләргә:

торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләре акчалата-субсидияләр-ташламалар рәвешендә бирелә;

субсидия-ташламалар арттырылган күләмдә бирелгән очракта, субсидия-ташламаларның санап үтелгән суммасы киләчәк чорның субсидия-ташламалары исәбенә исәпләнә. Социаль яклау органнары яисә Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәгенең филиаллары киләчәктә субсидия-ташламалар алуга хокук булмаганда, субсидияләрнең артып калган суммаларын кире кайтаралар. Субсидия-ташламалар алуны нигезсез рәвештә кире кайтару субсидия алучы тарафыннан ирекле рәвештә, ә ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта - Россия Федерациясе законнары нигезендә социаль яклау органының яисә Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәгенең филиалының дәгъвасы буенча башкарыла.

3. Хисап аеннан соң килүче айның 2 числосына кадәр мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр субсидия-ташламалар алу хокукын югалткан гражданнар исемлекләрен (компенсация түләүләре) Республика матди ярдәм үзәге филиалына, шул исәптән эштән китүгә бәйле рәвештә, тапшыралар.

Бирелә торган мәгълүматның үз вакытында һәм дөрес булуы өчен җаваплылыкны мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе муниципаль учреждениесе җитәкчесе башкара.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасына бюджет формалаштырганда район бюджетының өстәмә чыгымнарын каплау чыганакларын билгеләргә.

5. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 августындагы 468 номерлы карары;

«Аерым категория гражданнарга социаль ярдәм чаралары буенча аерым муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 гыйнварындагы 15 номерлы карары.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1061672000609 ИНН 1617003116